# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) икенче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

б) тугызынчы абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

в) егерменче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

г) кырык бишенче абзацта “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

2) 8 статьяның 1 өлешендәге егерме өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 21 статьяда:

а) 1 өлештә:

“табигать” сүзен төшереп калдырырга;

“калдыклар белән эш итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы” сүзләрен “хуҗалык һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка китерә торган” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Хуҗалык һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка китерә торган индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш) калдыклар барлыкка китерү нормативларының һәм аларны урнаштыру лимитларының проектларын эшлиләр. Хуҗалык һәм башка эшчәнлек нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка китерә торган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнарына яисә Татарстан

Республикасы башкарма хакимият органнарына хәбәр итү тәртибендә калдыклар барлыкка китерү, аларны куллану, зарарсызландыру, урнаштыру турында үз компетенцияләре нигезендә хисап тапшыралар.";

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Калдыклар барлыкка китерү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау, калдыклар барлыкка китерү, аларны куллану, зарарсызландыру, урнаштыру турында хисап тапшыру һәм аны контрольдә тоту тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.";

4) 34 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) "Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында" 2001 елның 8 августындагы 128-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан лицензияләнә торган аерым төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензияләрне нигезли торган материаллар (калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләрне нигезли торган материаллардан тыш);";

5) 36 статьяның 5 өлешендәге икенче абзацында "табигать" сүзен төшереп калдырырга;

6) 40 статьяның алтынчы абзацында "банк оешмаларына" сүзләрен "кредит оешмаларына" сүзләренә алмаштырырга;

7) 41 статьяда "табигать" сүзен төшереп калдырырга;

8) 83 статьяның 8 өлешендә "табигать" сүзен төшереп калдырырга;

9) 111 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"111 статья. **Үсемлекләр дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклау**

1. Үсемлекләр дөньясы объектларының яшәү тирәлеген, аларның вегетация һәм үрчү шартларын үзгәртүгә китерә торган теләсә нинди эшчәнлек үсемлекләр дөньясын саклауны тәэмин итә торган таләпләрне үтәгән килеш гамәлгә ашырылырга тиеш.

2. Торак пунктларны, предприятиеләрне, корылмаларны һәм башка объектларны урнаштырганда, проектлаганда һәм төзегәндә, гамәлдәге технологик процессларны камилләштергәндә һәм яңаларын гамәлгә керткәндә, сазлыклы, яр буендагы һәм куаклы территорияләрне хуҗалык әйләнешенә керткәндә, җирләрне мелиорацияләгәндә, урманнардан файдаланганда, геологик эзләнү эшләрен башкарганда, файдалы казылмалар чыгарганда, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү итеп йөртү өчен урыннар билгеләгәндә, туристлык маршрутларын эшләгәндә һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын оештырганда һәм хуҗалык эшчәнлегенең башка төрләрен гамәлгә ашырганда үсемлекләр дөньясы объектларының яшәү тирәлеген саклау чаралары күздә тотылырга һәм үтәлергә тиеш.

3. Фәнни яктан һәм хуҗалык ягыннан әһәмиятле үсемлекләр дөньясы объектларын саклауны тәэмин итү максатларында махсус саклау режимы билгеләнә торган махсус сакланылучы табигать территорияләре һәм акваторияләр бүленеп бирелергә мөмкин.";

10) 118 статьяның алтынчы абзацында ", урман фондын биләүчеләр" сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 126 статьяның 2 өлешендә "урманнардан файдалануны гамәлгә ашырганда" сүзләрен "урманнардан файдаланганда" сүзләренә алмаштырырга;

12) 140 статьяның дүртенче абзацында “табигать” сүзен төшереп калдырырга;

13) 160 статьяның 1 өлешендә “шул исәптән” сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 164 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“164 статья. **Калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү**

Калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү “Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында” 2001 елның 8 августындагы 128-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

15) 165 статьяның 2 өлешендә “һәм дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе булганда” сүзләрен төшереп калдырырга;

16) 166 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“166 статья. **I-IV классլы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалауга таләпләр**

1. I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалау законнар нигезендә түбәндәге шартлар булганда гамәлгә ашырыла:

I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларның паспорты булу;

махсус җиһазланган һәм махсус тамгалар белән тәэмин ителгән транспорт чаралары булу;

I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспорт чараларында транспортировкалауга иминлек таләпләрен үтәү;

I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспортировкалау һәм тапшыру өчен документация булу, анда транспортировкалана торган I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларның саны, аларны транспортировкалауның максаты һәм илтеп җиткерү урыны күрсәтелгән булырга тиеш.

2. I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны транспорт чараларында транспортировкалау тәртибе, I-IV класслы хәвефлелектәге калдыкларны төяү-бушату эшләренә, аларны төргәкләргә төрүгә, маркировкалауга таләпләр, экологик иминлекне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә таләпләр калдыклар белән эш итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан үз компетенцияләре нигезендә эшләнгән һәм расланган дәүләт стандартлары, кагыйдәләр һәм нормативлар белән билгеләнә.”;

17) 168 статьяның 1 өлешендә “табигать” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 16 мае
№ 20-ТРЗ